# Мәктәп хәбәрчесе

**№7 (№48) сентябрь 2023 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


*/Мөхәррир минбәре/*

## Белем бәйрәме



Туган авыл, мәктәп һәм әти-әниләр өчен Белем бәйрәменнән дә матур, күңелле бәйрәм юктыр. Быелгы 1нче сентябрь дә елдагыча тантаналы төстә һәм үзенә генә хас бер дулкында узды.

Тантаналы бәйрәмне мәктәп директоры котлау сүзләре белән башлады. Алдагы уку елында булачак яңалыклар белән кыскача таныштырды. Агымдагы уку елында мәктәп алдында торган максат, бурычларны билгеләде. Мәктәпкә яңа эшкә килгән тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Мифтахова Гөлия Дамир кызы белән таныштырды.

Бәйрәм барышында кунакларга бер –бер артлы сүз бирелде. Район вәкиле Сәхәбетдинов Мансур Шамил улы укучыларны котлап, илебез өчен кирәкле шәхесләр булып үсуләрен теләде. Җирле үзидарә җитәкчесе Хөснуллина Энҗе Мидхәт кызы да укучыларга тырышлык, укытучыларга сабырлык теләп, киләчәк балалар кулында икәнлеген тагын бер кат искәртеп үтте. Бәйрәмгә килгән ветеран укытучылар балаларга тырышып укуларын, сәламәт булуларын теләп, хәер-фатихаларын бирделәр. Исмагилов Рафик абый быел да үз иҗатыннан мәктәпкә, укучыларга багышлаган шигырен укыды.

Бәйрәм түрендә нинди генә матур сүзләр әйтелсә дә, чыгарылышлар моңлы һәм дулкынландыргыч җырлары, аларның инде тиздән зур тормышка юл алачакларын искә төшерде. Аларга алмашка килүче беренче сыйныф укучылары түргә узгач, бәйрәм яңадан күңелле төсмер алды. Сабыйларның самими чыгышлары һәрвакыттагыча мәктәпнең киләчәге өчен өмет уята.

Бәйрәм күңелле чәй табыны артында дәвам итте. Ветеран мөгаллимнәр, әти-әниләр, укытучылар өстәл артында җылы әңгәмә корып, бәйрәм истәлекләре белән уртаклаштылар. Ветераннар өчен бу очрашулар тагын да мөһим. Чөнки яшьлекләре узган эш урыны – иң якын һәм күңелле истәлекләрне барлау урыны да.

Бәйрәмебез түрендә булган һәр укучыга укуларында зур уңышларга ирешеп, сау-сәламәт булып, белем үрләрен зур тырышлык белән яулауларын телибез.

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*

## Олы бәйрәм

Бүген бездә олы бәйрәм
Дулкынланып көткән көн.
Китап-дәфтәрләрне тотып
Килдек алырга белем.

Мәктәбебез көлеп тора
Бүлмәләр якты, чиста!
Үтсен мәктәп елларыбыз
Дуслыкта, тырышлыкта.

Елмаеп каршы алдылар
Безне абый-апалар.
Биреп белем, һөнәрләргә
Өйрәтер безне алар.

Белем илендә яшәрбез
Елмаеп, шатланышып.
Үзләштерербез белемне
Иренмичә, тырышып.

Бирсен безгә һәр яңа көн
Яңа ачыш, шатлыклар!
Терәк булсын укуларда
Мөгаллимнәр һәм дуслар!

Мөгаллимнәр биргән сабак
Тормышта булсын маяк.
Сикәлтәле юлларында
Барырга туры атлап.

Уку гына түгел,мәктәп
Яшәешнең үл үзе.
Алдагы тормышта кирәк
Мөгаллмнең һәр сүзе.

Бергәләшеп, сау-сәламәт
Мәктәпләргә йөрик без.
Яулар бетсен, күкләр аяз,
Тыныч булсын илебез!

*Ветеран укытучы*
*Рафик Исмәгыйлев*

## Тәрбиячеләр көне белән!



27 сентябрь — тәрбиячеләр көне буларак билгеләп үтелә. Баланың якын дусты, сердәшчесе, тормышка беренче адымнарын ясарга ярдәм итүче мөгаллиме аерым игътибарга лаек!

Нәниләр өчен тәрбияче икенче әнидер. Бакча – иң җылы өйгә тиңдер. Анда сине яратучы апалар эшли. Сабыйны кашык тотарга, яңа сүзләр әйтергә, беренче тапкыр сәхнәдә чыгыш ясарга өйрәтүчеләр дә Сез. Сезгә бу авырлыкларны җиңәргә сабырлык телибез. Авазлардан гына торган теләкләрен аңларга зирәклек телибез. Эшегездә бары уңыш елмайсын. Сез үстергән, тәрбияләгән балалардан рәхмәтләр генә ишетелсен!

Шушы бәйрәм белән бергә бакчабыз тәрбиячесе Насыйрова Гөлүсә апаны **“Телләрне, мәдәниятләрне һәм гореф-гадәтләрне саклаган һәм үстергән өчен”** билгесенә ия булуы белән котлап, киләчәктә дә авыр һәм җаваплы хезмәтендә зур уңышларга ирешүен телап калабыз!

*“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе*

*/Укучылар иҗаты/*

## Җир ничек барлыкка килгән?



Яктылык белән Караңгылык күктә яшәгәннәр. бервакыт алар икесе дә түбәнгә караганнар. Аста диңгез генә җәелеп яткан. Андагы бушлыкны ничек тутырырга дип Яктылык белән Караңгылык озак уйлаганнар. Иң элек бу диңгезне җанландырырр өчен суда батмый торган җан иияләре уйлап чыгарганнар. Балык дигән хайванны тапканнар да, суга җибәргәннәр. Тик балыклар бертөрле генә булгач, ризык табарга читен булганлыгын аңлаганнар. Шулай итеп балыкның да төрлесен уйларга туры килгән. Бераз вакыт узгач, Яктылык белән Караңгылык тагын күңелсезләнгәннәр. Диңгез төбенәрәк якынлашып караганнар. Шунда аяк басарга уңайрак дип, ярларын да барлыкка китергәннәр. Яктылык күп тәшкән җирдә яшеллекләр үсеп чыга башлаган. Тик аларга нидер җитмәгәнен тиз аңлаган яктылык. Кире күккә күтәрелеп, Караңгылык белән киңәшкән. Ул үзе генә калган вакытта суык булганын, үләннәр үсмәгәнен аңлатып бирә. Икәүләшеп уйлагач, җылы кирәклеген аңлыйлар. Караңгы белен Яктылык күктәге күршеләре барлыгын белеп алып, Җылылыкны эзләп йөзеп киткәннәр. Озак эзли торгач, Кояшны табып, нурларын җибәрүләрен үтенеп сораганнар. Кояш бик теләп ризалашкан. Бераздан алар башка төрле җан ияләре кирәклелегенә дә төшенәләр. Табигатьнең һәр катына тереклек иңдерәләр болар. Туфракта яшәүче бөҗәктән алып, күктә очучы кошларга кадәр барлыкка китерәләр. Төрле җанварлар, кошлар барлыкка килгәч, инде диңгез тирәсенә генә сыешмагач, коры җирне зурайтып җибәрәләр. Кояшка күрше булып, араларын ерак итеп, Җирне барлыкка китерәләр. Шул көннән алып Яктылык белән Караңгылык үзләре барлыкка китергән Җирне чиратлашып карап торалар икән.

*Ләйсән Закирова,VI сыйныф укучысы*

## Интернет иясе




Интернет иясе бик күңелле зат. Син нәрсә сорасаң да, бик тиз генә җавап бирә. Сине яратып та өлгерсә, син теләгән әйберләрне генә чыгара ди. Интернет иясе, аның белән бергә күп вакыт үткәрүчеләрне бигрәк тә нык ярата.

Үз эченә бөтереп алып керәп китә дә, вакытны тиз үткәрергә ярдәм итә. Төрле уеннар уйнасаң, башыңда буш урын калмый. Синең башың да шундый “ризык” белән тула. Әйтерсең яраткан чипсы ашыйсың. Әле ул сиңа бернчә гомер дә бүләк итәм дип ышандыра. Интернет белән артык дуслашсаң, сине мошенниклар да якыннан белергә мөмкин. Алар сиңа төрле уен рекламалары чыгарып, һәрвакыт үз кармагында тотарга тырыша. Синең турыңда бөтен мәгълүмәтне белеп алып, бик оста файдаланырга мөмкин. Үз исәбенә, әлбәттә! Әгәр бик озак та утырсаң, кадерле вакытның үзуын да белми калуың бар. Башыңны күтәрсәң берзаман, әниең кушкан эшләрең эшләмәгәнең дә, инде аның эштән кайтыр вакыты җиткәнен дә онытып җибәргәнеңне аңлыйсың. Интернет иясе моны белеп эшли.

Тик интернет икенче төрле дә була ала, имеш. Әгәр кирәкле нәрсәләр генә эзләсәң! Парольләреңне дә онытмый, син теләгән кушымталарны да тиз табарга ярдәм итә. Өй эшләрен эшләгәндә өстәмә мәгълүматны эзләргә дә җиңеллек бирә.

Сез интернет иясенең кайсы сыйфатын сайлыйсыз? Минә шундый ул интернет иясе.

*Кәүсәр Насыйрова, VI сыйныф укучысы*

*/Күңелле тәнәфес/*

## Кызыклы сораулар

1. Яшелчә бакчасында бабай, әби, онык, эт мәче, тычкан шалкан тарталар. Бакчада ничә кеше?
2. Кубикның һәр ягы төрле төскә буялган. Моның өчен ничә төрле буяу кирәк?
3. Машинага биш кәҗә бәтие утырган. Һәрберсенең 8 км юл үткәнлеге билгеле. Машина күпме юл үткән?
4. Каз һәм мәче аякларының саны 8 булса, ишек алдында ничә каз бар?
5. Бер рәттә 8 урындык. Алсу сулдан бишенче урынга, ә Сания уңнан бишенче урынга утырган. Алар икесе бер урынга туры килмәгәннәрме?
6. Җәй көне самолет Уфадан Мәскәүгә 95 минут, ә кышын 1сәгать 35 минут оча. Бу ни өчен шулай?
7. Алмазның 7 таякчыгы бар. Бер таякчыкны урталай сындырса, аның ничә таякчыгы булыр?
8. Каз бер тәпиендә басып торганда 5 килограмм, ике тәпиенә басса ничә килограмм булыр?


**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин



## Сыйныфтан тыш чаралар

3 нче сентябрьдә террорчылыкка каршы көрәштә теләктәшлек көнендә мәктәбебез “Яшәү тамчысы” дип аталган бөтенроссия акциясенә кушылды. Бу көн 2004 нче елның 1 сентябрендә булган фаҗигале вакыйгаларга багышланган. Бу акция терракта һәлак булган кешеләр белән символик рәвештә су белән уртаклашырга тәкъдим итә.

Узган санныбызда мәктәптәге төп яңалыкларның берсе — “Үсеш ноктасы” (“Точка роста”) үзәге программасы турында язган идек. 5 нче сентябрьдә мәктәптә тантаналы рәвештә информатика, химия, биология кабинетлары ачылды. Бу үзәк безнең укучыларга күбрәк мөмкинлекләр бирер, балалар фән өлкәсендә күбрәк яңалыклар алырлар дип ышанабыз.




Шулай ук 5 нче сентябрьдә ЮИД түгәрәге укучылары, җитәкчеләре Гафиятуллина Руфия апалары белән берлектә, юл йөрү кагыйдәләрен искә төшереп үттеләр. Авыл эченнән уза торган юлда урнаштырылган тамгаларны кабатладылар. Автобуста йөрү кагыйдәләрен хәтердә яңарттылар.

Шушы ук атнада Халыкара белемлелек көненә багышланган чаралар узды. Бу дәрес халыкның белемлелеген арттыру максатыннан билгеләнгән. Бу кысаларда сыйныфлар өчен төрле чаралар уздырылды. Белемле булу өчен укучылар төрле ысулларны барладылар.

Быелгы уку елында да “Мөһим сөйләшүләр” (“Разговоры о важном”) алып барыла. 7 нче сентябрьдә һөнәри юнәлеш бирү курсының 1 нче дәресе узды. Бу курс һәр атнаның пәнҗешәмбесендә уздырылачак. Бу дәрестә төрле һөнәрләр белән танышачаклар.

***Гөлия Мифтахова, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***

**/Безнең сәяхәтләр/**



## Экологик экскурсия

Безнең мәктәпнең бер яхшы, барыбыз да көтеп алган гадәте – табигатькә сәяхәт. Ел саен туган ягыбызның бер почмагына ял итәргә барабыз. Башка елларда Рафик абый тарихи урыннарга алып барса, быелгы сәфәребез экологик юнәлешле булды. Биләр урманчылыгы соравы буенча үзебезнең мәктәп посадкасына агачларның яфракларын ашаучы кортлар белән көрәшергә бардык.

25 нче сентябрь иртәсендә экскурсиягә әзерләнеп килдек. Гадәттәгечә автобус һәм велосипедлар белән юлга кузгалдык. Барып җитүгә урман хуҗалыгы җитәкчесе Рамил абый агачларның быелгы җәйдә корткыч бөҗәкләрдән бик зур зыян күргәннәре турында сөйләде. Киләсе елга бу куркынычны бераз булса да киметү өчен, шул күбәләкләрнең салып калдырган йомыркаларын бетерергә кирәклеген аңлатты.

Эш тәртибе белән таныштыргач, барыбыз да чиләкләребезне, майлы пумалаларыбызны алып, парлашып агачлар арасына таралыштык. Эшебез кортларның йомырка салган оялары май белән буяп йөрүдән гыйбарәт иде. Ул хезмәт авыр булмады, эшебезне бик теләп башкардык. Шушы файдалы эшне башкарып, агачлар да кеше ярдәменә мохтаҗ икәнлегенә тагын бер кат ышандык. Бәлки быелгы кортлар явыз кешеләрнең табигатькә карата битарафлыгы өчен кисәтү булгандыр. Чөнки без анардан күп алсак та, җавап итеп чүп-чардан кала әллә ни биргәнебез юк бит. Бу экскурсиядә башкарган эшебез белән моннан 20 ел элек үзебезнең мәктәп укучылары утырткан агачларны күпмедер дәрәҗәдә корып бетүдән саклап калганбыздыр диеп ышанасы килә.

Без эшебезне тәмамлап килгәндә укытучы апаларыбыз казанда уха пешергәннәр, компот кайнатканнар иде. Уха пешерер өчен балыкны укучылар да, укытучылар да алып килде. Балык күп җыелгач, аш та бик тәмле булды. Пешерүче апаларга рәхмәтләр әйтеп, тамак ялгадык. Тәмле компот белән дә сыйлангач, төрле хәрәкәтле уеннар уйнадык. Саф һава сулап, файдалы хезмәт башкарып кайттык дия алам бу көнне. Алдагы елларда, урманчылар соравыннан башка да, табигатьне сакларга чакырам.

***Камил Төхвәтуллин, VI сыйныф укучы***

**/Безнең сәяхәтләр/**

## Майна елгасына сәяхәт

Һәр елны җәй айларында әтием безне туган ягыбызның матур урыннарын күрсәтергә алып чыга. Сәяхәт вакытында ул җирләр турында кызыклы тарихи хикәяләр сөйли. Урман-болыннарда үскән җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбәләрне җыярга өйрәтә.



Быел без сәяхәткә 17 нче сентябрь көнне чыктык. Максатыбыз – безнең авылга исем биргән Майна елгасы буйларын өйрәнү иде. Бабай безне машина белән Чиялек янына илтеп калдырды. Шуннан торып сәфәребезнең җәяүле өлеше башланды. Ул көнне иртәдән үк табигать кояш нурында коена. Агач яфраклары алтын-сары, кызыл, көрән төскә кергән, ә кайсылары әле җәйге яшеллеген саклап калган.

Без юлыбызны башлаган Югары кыр битеннән офыкка кадәрге бөтен җирләр бик яхшы күренә. Әти безгә шушы кырда моннан 300 еллар элек Иске авыл булганлыгы турында сөйләде, аның чикләрен күрсәтте. Төрле тарихи язмаларда бу авыл “Майна”, “Чирмешән” һәм “Салкын Чишмә” дигән исемнәр белән аталган икән. “Чирмешән” атамасы елгадан, “Салкын Чишмә” – авыл яныннан чыккан зур чишмәгә күрә кушылган. Ә “Майна” атамасының чыгышын әле ачыклыйсы бар, диде әти.

Югары кыр битеннән без Майна елгасы Чирмешәнгә кушылган җиргә төштек. Мондагы калку урында 1330-1350 нче еллар тирәсендә кечерәк кенә бер авыл булган икән. Әти, үзе уздырган тикшеренүләр буенча, бу урыннан чыккан табылдыклар Иске авылдагылар белән бертөрле үк диде. Шуңардан чыгып, безгә ни өчен Иске авылга “Майна” исеме кушылганын ачыкларга кушты. Апамнар белән уйлашканнан соң, без Майна буендагы бу авылдан кешеләр Иске авылга күченгәндер дигән фикергә килдек. Әти үзе дә шулай уйлаганын әйтте.



Майна тамагындагы авыл урыныннан без “Гәрлинкә” дип аталган тирән чокырга кердек. Ерым буйлап барып андагы сихри урыннар, болытларга тиеп торган озын агачларны күрдек. Бу чокыр берүк вакытта шомлы да, матур да иде. Биредә без элек бакыр эретү өчен файдаланылган көрән төстәге комташлы ярны карадык. Мин бу ярдагы куышка кереп тә карадым.

Гәрлинкә чокырыннан өскә чыгып, яңадан Майна елгасы буена төштек. Яр буендагы чытырманнарны аралап елганың аргы ягына чыктык. Аның үзәнендә ял итеп, чәйләр эчеп, ашап алдык. Шунда мин үземнең бик арыганлыгымны сиздем. Ләкин, шуңа да карамастан, без елга буйлап сәяхәтебезне дәвам итек.

Майна елгасының Чирмешәнгә кушылган турысында су бик сай иде. Без башта моның сәбәбен белмәдек. Бара торгач кондызлар төзегән дүрт буаны күрдек. Ул хайваннар анда бик калын агачларны да кимереп екканнар. Кондызлар буган урыннарда елганың суы шактый киңәйгән. Мин ул турыда елга аркылы кондызлар аударган агач буйлап чыктым.

Кондызлар оялаган җирдән бераз киткәч, кешеләр төзегән буага килеп чыктык. Ул буадан өстә су тагын да киң, тирән һәм бик чиста иде. Кайбер урыннарда кечкенә балыкларның уйнап йөзгәне бик яхшы күренеп тора. Без шунда кулларны, битләрне юып хәл алдык. Елга ярындагы куаклар арасыннан барырга кыен булганлыктан, биек яр өстендәге кырга мендек. Бик зур булган бу кырның өсте күпсанлы ташлар һәм чүлмәк кителкләре белән капланган иде. Әти бу урында Болгар заманында зур бер авыл булганлыгы турында әйтте. Борынгы авыл торган кырдан яңадан елга буена төшкәч, аның суы кибеп беткәнлеге күренде.

Аннан соң без бик киң, тигез һәм ямь-яшел чирәмле болынга җиттек. Анда бераз ял иткәч, юлыбызны дәвам иттек. Бара торгач, Майна Башы авылы янындагы күпергә һәм асфальт юлга килеп чыктык. Безне анда бабай машина белән көтеп тора иде. Җәяүләп барлыгы 7 чакрымнан артык йөргән булып чыктык. Бик арысак та, сәфәребездән риза булып әтигә, бабайга рәхмәтләр әйтеп өйгә кайтып җиттек. Бу сәяхәт минем күңелемдә мәңге сакланыр. Туган җиребезнең кадерен белеп яшәсәк иде!

***Кәусәр Насыйрова, VI сыйныф укучысы***

**/Котлыйбыз!/**



Сентябрь аенда туган көнен билгеләп үтүче 6 нчы сыйныф укучысы Төхфәтуллин Камилне чын күңелдән котлыйбыз. Дустыбызга саулык-сәламәтлек, укуында зур уңышларга ирешүен телибез.

Җитәкчебез Насыйров Рафик Гомәр улын да гомер бәйрәме белән котлап, ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, эшләрендә уңышлар теләп калабыз.